**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге советының 2018 елның 11 ноябрендәге 160 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында»Матюшино авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 августындагы 35 номерлы карары белән, яшәү өчен уңайлы шартлар, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокукына ия булучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан чыгып, Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге башкарма комитеты хәбәр итә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча 2021 елның 30 августыннан 2021 елның 15 октябренә кадәр гавами тыңлаулар уздыру турында;

Проектның мәгълүмати материаллары:

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;
- җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;
- җирлекнең функциональ зоналары картасы.
- җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге.
- Генераль планны нигезләү материаллары.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар

дип Матюшино авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре танылa.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проекты экспозициясе Интернет мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында https://laishevo.tatarstan.ru/matyushinskoe-sp-5527249.htm(веб – адрес буенча) «Генераль план проекты экспозициясе " өстәмә битендә, шулай ук, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Матюшино авылы, Березовая ур., 25й. Адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында ачылачак. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Интернет мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендәге веб – адрес буенча урнаштырылган проект материаллары белән https://laishevo.tatarstan.ru/matyushinskoe-sp-5527249.htm экспозициянең бөтен вакыты дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проект белән 20021елның 10 сентябреннән-20021елның 25 сентябренә кадәр, 13:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин.

4. Ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары уздырылачак:

- Матюшино авылында 20021елның 15 сентябрендә 10:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Матюшино авылы, Березовая ур., 25 йорт - авыл советы бинасында;

Яңа коронавируслы инфекция таралуны булдырмас өчен, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары профилактик чаралар үтәү белән үткәреләчәк.

3 пунктында күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы::

- язмача рәвештә, түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар оештыручы исеменә: Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Матюшино авылы, Березовая урамы, 25 й.

- Татарстан Республикасы, Матюшино авылы, Березоваяд урамы, 25 адресы буенча проект экспозициясен күргәзмәгә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналында) язу юлы белән..

Шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең генераль планы проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән бирелергә мөмкин.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.
Ачык тыңлауларда катнашучылар идентификацияләү максатларында үзләре турында белешмәләрне (фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), туган көнен, яшәү (теркәү) урынын - физик затлар өчен; исеме, Төп дәүләт теркәү

номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен), мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып тапшыралар. Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар хокукына ия булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар турында белешмәләр һәм күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгеләүче яисә раслаучы башка документлар тапшыралар.

Ачык тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз ризалыкларын бирәләр».

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

**Җитәкче** **Н.И.Миннуллина**